СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 8-17 от « 09 » ноября 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 ноябрендәге № 3-29 (23.07.2019 №13-34, 30.06.2020 №18-39, 10.06.2021 №1-7 редакциясендә) карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Красная Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге №468-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 - ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Красная Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 ноябрендәге № 3-29 (23.07.2019 №13-34, 30.06.2020 №18-39, 10.06.2021 №1-7 редакциясендә) карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Красная Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 .1. 29 статьяда:

- «Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның иң чик параметрлары» таблицасында «Күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте» ндә «Аерым бер гаилә торган йорт» параметрларына җир кишәрлекләренең иң чик параметрларының минималь мәйданын - 1000 кв.м., дип билгеләргә, шәхси хуҗалык алып бару өчен файдалану рөхсәт ителгән яисә шәхси торак төзелеше төре белән кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләрен бүлеп бирү юлы белән, мәйданы 1000 кв. метрдан ким булган җир кишәрлекләре барлыкка килүдән тыш.

2. Әлеге карарның 1 пунктында каралган җир кишәрлекләренең чик минималь күләме гражданнарга әлеге карар рәсми рәвештә үз көченә кергәннән соң бирелә торган җир кишәрлекләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында каралган җир кишәрлекләренең иң чик минималь күләмнәрен әлеге карарны кабул иткәнче гражданнарга аренда хокукларында бирелгән һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә милек итеп сатып алына торган җир кишәрлекләренә кагылмый дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының Җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
башлыгы, Совет рәисе — А.П. Иванов